**ГЛАВА СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Суксу, ул. Школьная, 9А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9А

тел./факс 8(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**25 март 2024 ел** **№ 6**

**Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Зур Рәс торак пунктында авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 06 октябрендәге Федераль законның 25.1, 56 статьяларына ярашлы № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе, нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Зур Рәс торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 05.04.2024 елга билгеләргә. Үткәрү вакыты 16 сәгать 00 минутта. Утырыш урыны: ТР, Биектау районы, Зур Рәс авылы, Күлле урамы, 12 йорт каршында.

1.1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Зур Рәс торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 23 октябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы: «2024 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Биектау районы Суыксу авыл җирлеге Зур Рәс торак пунктында теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Зур Рәс торак пунктында җирләү урыннарын тоту.»

2023 елның 23 октябрендәге 2 номерлы карарда күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эшләргә үзгәртү:

- ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Олы Рясь торак пунктында җирләү урыннарын тоту)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев